**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

8 ноябрь, 2022 ел №106

**«Җир салымы турында»гы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 105 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге карарының 5 пунктына, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге Советы карарының 5 пункты нигезләмәләренең гамәлдә булуы (әлеге карар редакциясендә) 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Каратун авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р.С.Исмагилов**